**«ИСТОРИЧЕСКАЯ ЭТНОЛОГИЯ» журналы**
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты
420111 Казан шәһ., Батурин ур., 7
Тел./факс +7(843) 292 84 82
E-mail: his.ethnology@gmail.com

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ МӘКАЛӘЛӘРНЕ ӘЗЕРЛӘҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

(15.04.2024 яңартылды)

## ЭЧТӘЛЕК

I. Журналга бирелә торган материаллар турында гомуми мәгълүмат
II. Мәкаләнең формасы
III. Фәнни дәрәҗәләр һәм вазифаларның тәкъдим ителгән тәрҗемәләре
IV. Мәкалә текстын әзерләү
V. Библиографик аппаратны әзерләү кагыйдәләре:
- «Чыганаклар» исемлеген әзерләү кагыйдәләре
- «Әдәбият» исемлеген әзерләү кагыйдәләре
- Referencesны әзерләү кагыйдәләре

VI. Аннотацияне (автор резюмесын) әзерләү буенча киңәшләр
VII. Иллюстратив материал
VIII. График материал

## I. Журналга бирелгән материаллар турында гомуми мәгълүмат

**1.** *Телләр*: журналда татар, рус һәм инглиз телләрендәге мәкаләләр басыла.

**2.** *Формат*: материаллар электрон вариантта, MS Word DOC яки DOCX форматында кабул ителә.

**3.** *Күләм*: 30 меңнән алып 50 мең билгегә кадәр күләмдәге мәкаләләр кабул ителә (буш урыннар белән бергә). «Яңа китаплар» һәм «Фән дөньясы яңалыклары» бүлеге өчен 11 мең билгегә кадәр (буш урыннар белән бергә).

## II. Мәкаләнең формасы

**1.** Блок 1: мәкалә язылган телдә (татар яки рус телендә) язылa.
Мәкаләнең исеме (битнең уртасына, баш хәрефләр белән языла).
Автор(лар): (инициаллар, фамилия), битнең сул ягына языла.
Автор(лар) турында мәгълүмат: (оешма(лар), шәһәр, ил, электрон почта).
Аннотация (автор резюмесы), күләме 200-250 сүз.
Ачкыч сүзләр (6-8 сүз, өтер аша). Ахырда нокта куела.
Мәкаләгә сылтама ясау өчен: мәкаләнең библиографик тасвирламасы.

Мәкалә ике яки күбрәк автор тарафыннан язылган очракта, редакция белән хәбәрдә торачак авторның фамилиясе алдыннан йолдызчык билгесе куела.

**2.** Блок 2: инглиз телендә языла.
Мәкаләнең исеме (битнең уртасына, баш хәрефләр белән языла).
Автор(лар) (инициаллар, фамилия), битнең сул ягына языла.
Аннотация (автор резюмесы), күләме 200–250 сүз.
Ачкыч сүзләр (Keywords) (6–8 сүз, өтер аша).

Мәкаләгә сылтама ясау өчен (For citation): мәкаләнең библиографик тасвирламасы.

**3.** Блок 3:

Мәкалә тексты.

Рус һәм инглиз телләрендәге фразалар: «Авторлар мәнфәгатьләр конфликты булмавы хакында хәбәр итәләр» («Авторы заявляют об отсутствии конфликта интересов», «The authors declare no relevant conflict of interests»).

Чыганаклар (барлык мәкаләләрдә дә булмаска мөмкин)

Әдәбият

References – роман алфавиты нигезендә язылган татар, рус телләрендәге һәм башка сылтамалардан гыйбарәт фәнни әдәбият (Referencesны язу кагыйдәләре белән турында тулырак аста танышырга мөмкин).

Автор(лар) турында рус телендә белешмә: ФИО тулысынча, фәнни дәрәҗә, вазифа, оешма(лар), оешма(лар)ның почта адресы(лары) (индекс, урам, йорт, шәһәр, ил); ORCID (http://orcid/....), электрон почта.

Автор(лар) турында инглиз телендә белешмә: ФИО тулысынча, фәнни дәрәҗә, вазифа, оешма(лар), оешма(лар)ның почта адресы(лары) (индекс, урам, йорт, шәһәр, ил); ORCID (http://orcid/....), электрон почта.

Рәхмәт сүзләре (Acknowledgement).

**4**. Татар телендәге мәкаләләр өчен: 2 нче блок һәм аның рус телендәге тәрҗемәсе мәҗбүри.

Инглиз телендәге мәкаләләр өчен: 2 нче блок мәҗбүри, тик ул рус телендә бирелә.

**5.** Фәнни әдәбиятка, аналитик докладларга һәм мәкаләләргә сылтамалар текст эчендәге библиографик сылтамалар формасында түгәрәк җәяләр эчендә күрсәтелә, анда авторның фамилиясе, хезмәтнең басылып чыккан елы, бит(ләр)е күрсәтелә. Мәсәлән, (Хәкимов, 2016: 244). Библиографик тасвирламада фамилия күрсәтелмәгән очракта, текст эчендәге сылтамада хезмәтнең исемен күрсәтергә кирәк (әгәр исем озын икән, ул очракта, кыскартылып, өч нокта куела; тексттан соң бирелгән исемлектә тулысынча күрсәтелә). Текстта ике автор тарафыннан язылган хезмәткә сылтама ясаган очракта, ике авторның да фамилиясе күрсәтелә. Мәсәлән, (Миргалеев, Пашаоглу, 2014). Өч яки аннан да күбрәк авторлар тарафыннан язылган хезмәткә сылтама ясаганда, беренче авторның фамилиясен күрсәтергә һәм «һ.б.» дип, чит ил басмалары булган очракта «et al.» дип язарга кирәк. Мәсәлән, (Иванов һ.б. 2019: 15), (Petrov et al. 2012: 403). Текстта бер үк авторның бер үк елда язылган хезмәтләренә сылтама ясаганда, хезмәт басылып чыккан елга а, б, в, хәрефләрен (чит ил басмалары булган очракта, латин хәрефләрен - a, в, c) өстәргә кирәк. Мәсәлән, (Хәкимов, 1993а: 23; Хәкимов, 1993б: 32).

## III. Фәнни дәрәҗәләр һәм вазифаларның тәкъдим ителгән тәрҗемәләре

Cand. Sc. (Sociology) – фәннәр кандидаты.
Doctor Sc. (Sociology) – фәннәр докторы.
Leading Research Fellow – әйдәп баручы фәнни хезмәткәр.
Chief Research Fellow – баш фәнни хезмәткәр.
Senior Research Fellow – өлкән фәнни хезмәткәр.
Research Fellow – фәнни хезмәткәр.
Junior Research Fellow – кече фәнни хезмәткәр.
Corresponding Member, Академиянең исеме – Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы.
Member, Академиянең исеме – Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы.
Dean / Vice-Dean – декан / декан урынбасары.
Associate Professor – доцент.

## IV. Мәкалә текстын әзерләү тәртибе

**1.** Кегльнең зурлыгы – 14.
**2.** Шрифт – Times New Roman.
**3.** Стиль – гадәти.
**4.** Интервал – бер иңле.

**5.** Кырлар – 2 см.
**6.** Буш ара (отступ) – 0,8.
**7.** Искәрмәләр булган очракта, алар астөшермәләрдә, һәрбер биттә яңа нумерация белән куела.
**8.** Мәкалә текстында куштырнаклар «» күрсәтелә.
**9.** Тексттагы кыскартулар:

- гасыр/гасырлар, сан (цифр) янында торган очракта кыскартылалар. Мәсәлән, XIX г., XVII–XVIII гг.
- текстта беренче тапкыр искә алынганда, оешма, ил, төбәкләрнең тулы исеме, ә кабат кулланылганда кыскартылмасы (аббревиатурасы) бирелә. Мәсәлән, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты (алга таба – ТДГПУ).
- Архив материалларын бирү өчен түбәндәге кыскартылмалар кулланыла: ф. – фонд, тасв. – тасвиралама, эш – эш, кгз. – кәгазь. Аларны аңлатып язу таләп ителми.

## V. Библиографик аппаратны әзерләү тәртибе

### Гомуми таләпләр

**1.** Библиографик исемлекләрдә **бары тик** текстта сылтама ясалган хезмәтләр һәм материаллар гына күрсәтелә.

**2.** Норматив документларга, статистика материалларына һәм авторларның фамилияләре күрсәтелмәгән материалларга, шулай ук газета мәкаләләренә, интернет-битләргә сылтамалар һәрбер битнең астындагы искәрмәләрдә куела, мөрәҗәгать итү датасы языла.

**3.** Текстта башка чит телләрдән кергән (гарәп, фарсы һ.б.) авыр аңлаешлы сүзләр булган очракта, аларның тәрҗемәсе яки аңлатмасы әлеге сүзләрдән соң куш җәяләр эченә языла, курсив белән күрсәтелә: фазыйләт (*өстенлек*), хәмед (*мактау*) һ.б.

**4.** Искәрмәләр һәрбер битнең астында бирелә.

**5.** «Чыганаклар» һәм «Әдәбият» бүлекләрендәге исемлекләр алфавит тәртибендә языла, тәртип саннары күрсәтелми. Башта кириллицада (рус, татар, серб, украин һ.б. телләрдә), аннан соң латин графикасында (инглиз, француз һ.б.) язылган хезмәтләр бирелә.

**6.** Монографияләрнең нәшрият тасвирламалары тулысынча күрсәтелә (шәһәр: нәшрият, ел). Китапның гомуми бит саны күрсәтелми.

**7.** Журналдан яки җыентыктан алынган мәкаләләрнең беренче һәм соңгы битләрен күрсәтү мәҗбүри.

**8.** Фәнни җыентыкларның җаваплы мөхәррирен/мөхәррирләрен яки төзүчесен/төзүчеләрен күрсәтү мәҗбүри.

**9.** Журнал һәм башка вакытлы матбугат басмаларының исемнәре кыскартылмыйча, тулы килеш бирелә.

**10.** Темага аналитик фәнни күзәтү ясаган материал биргәндә, тулы библиографик исемлекне күрсәтү мәҗбүри.

**11.** «Яңа китаплар» бүлегендәге язмалар өчен «Әдәбият» исемлегендә бәя бирелгән китапның тулы нәшрият тасвирламасы бирелә. «Документлар» һәм «Яңа китаплар» сәхифәләренә караган материалларга әдәбият исемлеге бирелмәскә дә мөмкин.

**12.** Ике исемлектә бергә барлыгы 50 дән артык булмаган чыганактан файдаланырга тәкъдим ителә. Әдәбият исемлегендә үз-үзеңә сылтама 10% тан артык булырга тиеш түгел.

**13.** Библиографик исемлекнең аз күләмле булуы (биштән ким фәнни әдәбиятка сылтама) мәкаләне бастырмаска сәбәп булырга мөмкин.

### «Чыганаклар» исемлеген әзерләү тәртибе

**1.** «Чыганаклар» исемлегендә архив һәм экспедиция материаллары күрсәтелә.

**2.** Текстта «Чыганаклар» исемлегенә сылтамалар ясау өчен түгәрәк җәяләр эченә куелган «алкушымча» («префикс») (кара: аста) кулланыла.

**3.** Исемлек «алкушымча» («префикс») һәм чыганакның кабул ителгән библиографик тасвирламасы ярдәмендә әзерләнә.

**4.** Алкушымчага таләпләр:

- Архив материаллары өчен сылтама ясалган архивның кабул ителгән кыскартылмасын (ТР ДА, БР МА һ.б.) кулланырга тәкъдим ителә. Мәкаләдән соң «Чыганаклар» бүлегенә кадәр бирелгән «Кыскартылмалар исемлеге» бүлегендә кыскартылмаларга аңлатма бирергә кирәк.
- Текстта архивның исеме, фонд, тасвирлама, кәгазь күрсәтелә (ТР ДА. 316 ф. 1 тасв. 161 эш. 37-38 кгз.).
- Экспедиция материалларын биргәндә, АЭМ (авторның экспедиция материаллары) аббревиатурасын һәм аларны җыю елын күрсәтергә кирәк. Мәсәлән, (АЭМ 2000).
- Әгәр материалның елы бар икән, ул очракта аны алкушымчада күрсәтергә кирәк.

## «Чыганаклар» исемлегеннән мисаллар

*Архив документларын тасвирлау*

ТР ДА. 316 ф. 1 тасв. 161 эш.

Текстта сылтама шулай куела: (ТР ДА. 316 ф. 1 тасв. 161 эш. 37-38 кгз), әгәр документ кәгазьнең икенче ягында икән, (ТР ДА. 316 ф. 1 тасв. 161 эш. 37-38 кгз. и.я.) дип бирелә.

Әгәр бер үк фондның төрле эшенә сылтама ясарга туры килсә, шул рәвешле язарга мөмкин:

ТР ДА. 316 ф.

Текстта сылтама болай бирелә: (ТР ДА. 316 ф. 1 тасв. 161 эш. 37-38 кгз.).

*Гаилә архивларын тасвирлау*

*Гобәйдуллин А.Г.* Көндәлек (Кульязма) // Гобәйдуллиннар гаиләсе архивы. Казан (мөрәҗәгать итү датасы: 08.08.2018).

Текстта сылтама шул рәвешле бирелә: (Гобәйдуллин, 2018: 14).

*Экспедиция материаларын тасвирлау*

АЭМ 2018 – Авторның Татарстан Республикасы Биектау районында туплаган экспедиция материаллары, 2018 ел, июнь (1, 2 дәфтәрләр).

Текстта сылтама шул рәвешле бирелә: (АЭМ, 2018: Иванова), биредә Иванова – мәгълүмат бирүче.

## «Әдәбият» исемлеген төзү кагыйдәләре

**1.** «Әдәбият» исемлегендә бары тик фәнни хезмәтләр (монографияләр, фәнни җыентыклар, фәнни/академик басмалардагы мәкаләләр һәм бәяләмәләр) күрсәтелә.

2. Язмаларны библиографик тасвирлау: автор (курсив белән), язманың исеме, нәшрият тасвирламасы. Мәкаләнең DOIсы булган очракта, аны күрсәтү мәҗбүри.

## «Әдәбият» исемлегеннән үрнәкләр

*Монографияне тасвирлау*

*Гаффарова Ф.Ю.* «Йолдыз» кабызган Максуди. Казан: Алма-Лит, 2006.

*Җыентык мәкаләсен тасвирлау*

*Фәхреддин Р.* Мәрҗани // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 400–441.

*Журнал мәкаләсен тасвирлау*

*Сәлахова Э.К.* Г. Гобәйдуллин хезмәтләрендә «халык», «милләт» төшенчәләре // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 3. С. 457–467. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-3.457-467

*Диссертацияне тасвирлау*

*Вәһапов Н.Ә.* Татар вакытлы матбугатында мәгариф һәм тәрбия мәсьәләләре. Тарих фән. канд. ... дис. Казан, 2006.

*Электрон мәкаләне тасвирлау*

*Сәлахова Э.К.* «Касыймия» мәдрәсәсе тарихы // Татарский мир – Дзен. URL: https://dzen.ru/a/ZA-dveCegl_FYTyw?referrer_clid=1400& (мөрәҗәгать итү датасы: 16.02.2023).

## REFERENCES ИСЕМЛЕГЕН ТӨЗҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

**1.** «References» исемлегендә «Әдәбият» исемлегендәге барлык язмалар күрсәтелә. Исемлек инглиз алфавиты нигезендә төзелә.

**2.** Инглиз телендәге язмаларга библиографик сылтама оригиналда бирелә: авторлар, елы (түгәрәк җәяләрдә), язманың исеме (курсив белән), басма турында белешмә, битләре (монографияләрнең бит саны күрсәтелми). Чыганакның теле күрсәтелми. Электрон язмаларга мөрәҗәгать итү датасы инглиз телендә түгәрәк җәяләрдә күрсәтелә (accessed: 16.02.2023).

### References исемлегеннән инглиз телле язмаларны күрсәтү үрнәкләре:

*Монографияне тасвирлау*

Tajfel H., Turner J.C. (1986) The Social Identity Theory of Intergroup Behavior. In: Worchel S., Austin W.G. (eds) *Psychology of Intergroup Relations*. Chicago: Nelson-Hall: 7–24.

Etzkowitz H. (2008) *The Triple Helix: University-Industry-Government Innovation in Action*. New York: Routledge. 176 p. Available at: URL: http://mguntur.id/files/ebook/ebook_1605608206_cf742d707b4e0bf22bf3.pdf (accessed: 16.02.2023).

*Журнал мәкаләсен тасвирлау*

Yurchak A. (2000) Privatize your name: symbolic work in a Post-Soviet linguistic market. *Journal of Sociolinguistics*. No. 4 (3): 406–434.

**3.** Инглиз телендә булмаган (татар, рус һ.б. телләрдә) монографиягә, журнал, җыентык мәкаләләренә, конференция материалларына сылтама транслитерацияләнгән һәм шулай ук тәрҗемә ителгән өлешләрне үз эченә ала.

**4.** Татар сүзләренә транслитерация өчен татар теленең 2012 елгы рәсми транслитерация кагыйдәләре кулланыла (https://cdnstatic.rg.ru/uploads/attachments/73/99/43/pril.pdf).

Истә тоту мөһим:

- татар текстлары (хезмәт авторының ФИО, журнал яки җыентык исеме) өчен татар хәрефләрен латин хәрефләре белән алмаштыру кирәк.
- Том, басманың № инглиз телендә vol., no дип бирелә.
- Referencesta куштырнаклар “” билгесе белән күрсәтелә;
- Шәһәр исемнәре кыскартылмый: М. – Moscow; СПб. – St. Petersburg; Л. – Leningrad; N.Y. – New York һ.б. Шәһәр исеменнән соң нәшрият исеме алдыннан ике нокта куела.
- Чит ил авторларының исемнәре оригиналдагыча бирелә. Игътибар итегез: транслитератор Маркс фамилиясен Marks дип язачак (Marx дип үзгәртергә кирәк); Моссны Moss дип (тиеш: Mauss); Леви-Стросны Levi-Stros дип бирәчәк (тиеш: Lévi-Strauss).

**5.** *Рус телендәге монографиянең* библиографик тасвирламасы түбәндәге схема буенча башкарыла: автор (транслитерация), басылып чыккан елы (түгәрәк җәяләр эчендә), исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (курсив белән; әгәр мәкаләдә булмаса, үзебезнең тәрҗемәне куябыз), басылып чыккан урыны, нәшрияты. Монографияне тасвирлаганнан соң чыганакның исемен күрсәтергә кирәк (In Russ.). Нәшрият исеме инглиз теленә тәрҗемә ителә (Moscow St. Univ. Publ.) яки Publ сүзен кушып транслитерацияләнә. (GEOTAR-Media Publ., Nauka Publ.). Нәшрият исемендәге һәр сүзне баш хәрефләр белән язарга кирәк.

### References исемлегеннән рус телендәге монография үрнәге:

Karminskiy A.M., Peresetskiy A.A., Petrov A.E. (2005) *Ratings in Economics: Methods and Practice*. Moscow: Finance and Statistics Publ. (In Russ.)

6. *Рус телендәге журнал мәкаләсенең* библиографик тасвирламасы түбәндәге схема буенча башкарыла: автор(лар) (транслитерация), басылып чыккан елы (түгәрәк җәяләр эчендә), мәкалә исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (әгәр мәкаләдә булмаса, үзебезнең тәрҗемәне куябыз), журналның транслитерацияләнгән исеме (курсив белән), журналның инглиз телендәге исеме (квадрат җәяләр белән), нәшрият тасвирламасы (том, номер), битләре. Журналның инглиз

телендәге дөрес исемен күрсәтү өчен аның рәсми сайтына мөрәҗәгать итәргә киңәш итәбез. DOI булган очракта, аны библиографик тасвирламаның ахырында күрсәтергә кирәк. Мәкаләне тасвирлаганнан соң, аның телен күрсәтү таләп ителә (In Russ.). Электрон язмалардагы чыганакларга мөрәҗәгать итү датасы инглиз телендә түгәрәк җәяләр эчендә языла (accessed: 12.12.2016).

**References исемлегеннән рус телендәге мәкалә үрнәге:**

Baranova V.V., Fedorova K.S. (2020) Regulation of the language landscape in Russian cities: multilingualism and inequality. *Zhurnal issledovaniy sotsial'noy politiki* [The journal of social policy research]. Vol. 18. No. 4: 625–640. (In Russ.) https://doi.org/ 10.17323/727-0634-2020-18-4-625-640.

**7.** *Рус телендәге җыентык мәкаләсенең* библиографик тасвирламасы: автор(лар) (транслитерация), басылып чыккан елы (түгәрәк җәяләр эчендә), мәкалә исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (әгәр басылып чыккан җыентыкта булмаса, үзебезнең тәрҗемәне куябыз), җыентык исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (курсив белән), нәшрият тасвирламасы (том, номер), битләре. Мәкаләнең тасвирламасыннан соң аның телен күрсәтү таләп ителә (In Russ.). “//” урынына “In:” дип языла. Электрон язмалардагы чыганакларга мөрәҗәгать итү датасы инглиз телендә түгәрәк җәяләр эчендә языла (accessed: 2.08.2023). Авторлар һәм мөхәррир рус телендәге исемлектәге кебек үк, туры хәрефләр белән языла (курсив белән түгел).

**References исемлегеннән рус телендәге җыентык яки монографияләрдән алынган мәкаләләргә үрнәкләр:**

Dolgova A.P. (2002) To the question of the state of ergonymy in the conditions of bilingualism (on the example of the city of Cheboksary). In: *Onomastics and languages of the Ural-Volga region*: Proceedings of the regional conference. Cheboksary, November 13–14, 1997. Cheboksary: ChGIGN Publ.: 29–37. (In Russ.)

Mkrtchyan N.V. (2012) Problems of Counting the Population of Certain Age Groups during the 2010 Population Census: Reasons for the Deviations of the Received Data from the Expected Ones. In: Denisenko M.B. (eds) *Demographic aspects of socio-economic development*. Vol. 22. Moscow: MAKS Press Publ.: 197-214. (In Russ.)

Golomidova M.V. (2022) Municipal Toponymic Policy and Issues of Urban Toponymy Development. In: *International Round Table “Urbanization and Language Space of the City: New Challenges in the 21st Century”*. Moscow, September 19–20, 2022. URL: https://www.youtube.com/watch?v=XbhZk6ABjDg&list =PLMlxxldt8flovwZDnisdSIcU0DLT7A7Na (accessed: 25.11.22). (In Russ.)

**8.** *Диссертациянең* библиографик тасвирламасы**:** авторы (транслитерация), елы (түгәрәк җәяләр эчендә), исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (булмаган очракта үзебезнең тәрҗемәне язабыз), урыны. Ахырдан чыганакның телен күрсәтергә кирәк (In Russ.), (In Tat.), (In Ital.).

**References исемлегеннән рус телендәге диссертация үрнәге:**

Ismagilova G.Kh. (2011) *Linguistic features of visual and information attributes of the city in the framework of the implementation of the law on the languages of the Republic of Tatarstan*: Dis. cand. philol. sciences. Kazan. (In Russ.)

**9.** *Татар телендәге монографиянең* библиографик тасвирламасы түбәндәге схема буенча башкарыла: автор (транслитерация), басылып чыккан елы (түгәрәк җәяләр эчендә), исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (курсив белән; әгәр мәкаләдә булмаса, үзебезнең тәрҗемәне куябыз), басылып чыккан урыны, нәшрияты. Монографияне тасвирлаганнан соң чыганакның исемен күрсәтергә кирәк (In Tat.). Нәшрият исеме инглиз теленә тәрҗемә ителә (Moscow St. Univ. Publ.) яки Publ сүзен кушып транслитерацияләнә. (GEOTAR-Media Publ., Nauka Publ.). Нәшрият исемендәге һәр сүзне баш хәрефләр белән язарга кирәк.

**References исемлегеннән татар телендәге монография үрнәге:**

Gaffarova F.Yu (2002). *Akhmetkhadi Maksudi.* Kazan: Sh. Marjani Institute of History of TAS Publ., 2002. (In Tat.).

**10.** *Татар телендәге журнал мәкаләсенең* библиографик тасвирламасы түбәндәге схема буенча башкарыла: автор(лар) (транслитерация), басылып чыккан елы (түгәрәк җәяләр эчендә), мәкалә исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (әгәр мәкаләдә булмаса, үзебезнең тәрҗемәне куябыз), журналның транслитерацияләнгән исеме (курсив белән), журналның инглиз телендәге исеме (квадрат җәяләр белән), нәшрият тасвирламасы (том, номер), битләре. Журналның инглиз телендәге дөрес исемен күрсәтү өчен аның рәсми сайтына мөрәҗәгать итәргә киңәш итәбез. DOI булган очракта, аны библиографик тасвирламаның ахырында күрсәтергә кирәк. Мәкаләне тасвирлаганнан соң, аның телен күрсәтү таләп ителә (In Tat.). Электрон язмалардагы чыганакларга мөрәҗәгать итү датасы инглиз телендә түгәрәк җәяләр эчендә языла (accessed: 12.12.2016).

**References исемлегеннән татар телендәге мәкалә үрнәге:**

Zinnätullina A.Ä. (2021). School Foundation Ceremony in Memory of Fatima-Farida Nauruzova. *Istoricheskaya etnologiya* [Historical Ethnology]. Vol. 6. No. 2: 302–311. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-2.302-311 (In Tat.)

**11.** *Татар телендәге җыентык мәкаләсенең яки монографиянең* библиографик тасвирламасы: автор(лар) (транслитерация), басылып чыккан елы (түгәрәк җәяләр эчендә), мәкалә исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (әгәр басылып чыккан җыентыкта яки монографиядә булмаса, үзебезнең тәрҗемәне куябыз), җыентык яки монография исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (курсив белән), нәшрият тасвирламасы (том, номер), битләре. Мәкаләнең тасвирламасыннан соң аның телен күрсәтү таләп ителә (In Tat.). “//” урынына “In:” дип языла. Электрон язмалардагы чыганакларга мөрәҗәгать итү датасы инглиз телендә түгәрәк җәяләр эчендә языла (accessed: 2.08.2023). Авторлар һәм мөхәррир рус телендәге исемлектәге кебек үк, туры хәрефләр белән языла (курсив белән түгел).

**References исемлегеннән татар телендәге җыентык мәкаләләре яки монографияләргә үрнәкләр:**

Zinnätullina A.Ä. (2019) Fatyma-Farida Nauruzova and the “Sibiria” newspaper. In: Scientific heritage and social activities of the Maksudi brothers. Kazan: Sh.Marjani Institute of History of TAS Publ.: 82–87. (In Tat.)

**12.** *Диссертациянең* библиографик тасвирламасы**:** авторы (транслитерация), елы (түгәрәк җәяләр эчендә), исеменең инглиз теленә тәрҗемәсе (булмаган очракта үзебезнең тәрҗемәне язабыз), урыны. Ахырдан чыганакның телен күрсәтергә кирәк (In Russ.), (In Tat.), (In Ital.).

**References исемлегеннән татар телендәге диссертация үрнәге:**

Möxämmätşin F.M. (2007). Lexico-grammatical features of the newspaper «Nur». Dis. cand. philol. sciences. Kazan. (In Tat.)

## VI. Аннотация (автор резюмесы)[1] төзү буенча киңәшләр

Автор резюмесының төп максатлары һәм бурычлары. Автор резюмесы (АР) күләме буенча зуррак булган мәкаләнең кыска резюмесы. Ул журнал сайтында төп мәкаләдән башка урнаштырыла һәм, нәтиҗәдә, төп мәкаләгә мөрәҗәгать итми дә аңлашылырга тиеш. АР әлеге журнал кергән Россия һәм чит илләр мәгълүмат системаларында автор турында төп мәгълүмат чыганагы булып тора.

[1] Кириллова О.В. Редакционная подготовка научных журналов для включения в зарубежные индексы цитирования. **http://www.library.fa.ru/files/Kirillova.pdf** (дата обращения: 19.07.2023).

Автор резюмесының төзелеше, эчтәлеге һәм күләме.

- мәкаләнең төзелешенә туры килгән, андагы төп бүлекләрне: кереш, максат һәм бурычлар, методлар, нәтиҗәләр/тикшерү, нәтиҗәләр/йомгакны үз эченә алган АР төзелеше уңышлы дип табыла.
- эшнең нәтиҗәләре төгәл һәм мәгълүмати булырга тиеш. Төп нәзари (теоретик) һәм эксперименталь нәтиҗәләр, фактик мәгълүматлар, эш барышында табылган үзара бәйләнешләр һәм закончалыклар китерелергә тиеш. Яңа фәнни нәтиҗәләргә һәм автор карашы буенча гамәли әһәмияткә ия дип табылган мәгълүматларга өстенлек бирелергә тиеш.
- Нәтиҗәләрдә мәкаләдә тасвирланган киңәшләр, бәя, тәкъдимнәр, гипотезалар булырга мөмкин.
- мәкалә исемендәге мәгълүмат АР текстында кабатланмаска тиеш.
- АР текстында мәкалә текстындагы аеруча әһәмиятле сүзләр кулланылырга тиеш. Текст кыска һәм ачык, төгәл, икенчел дәрәҗәдәге мәгълүматтан, артык кереш сүзләрдән, гомуми һәм эчтәлеккә кагылышы булмаган гыйбарәләрдән азат булырга тиеш.

## VII. Иллюстратив материал

**1.** Мәкаләдә яхшы сыйфатлы аклы-каралы һәм төсле рәсемнәр бирергә мөмкин. Һәрбер рәсемне аерым файлда TIF, JPG форматында, 300 dpi дән дә ким булмаган разрешение белән җибәрергә кирәк. Мәкаләгә 5кә кадәр рәсем кабул ителә.

**2.** Авторлар рәсемнәрне текста урнаштыру буенча үзләренең теләкләрен белдерә алалар. Моның өчен текстта: БИРЕДӘ РӘС.1, БИРЕДӘ РӘС.2 дип күрсәтеп барырга кирәк (абзацлар арасындагы аралыкта).

**3.** Һәрбер рәсемгә мәгълүмати рәсем асты бирелә, аның чыганагы / авторы, иллюстрациянең ясалган вакыты, анда сурәтләнгән чор күрсәтелә. Рәсем асларын аерым файлда исемлек тәртибендә эшләргә һәм мәкалә белән бер үк вакытта редакциягә җибәрергә кирәк. График файл ярдәмендә эшләнгән рәсем аслары кабул ителми.

**4.** Мәкаләгә теркәлгән теләсә кайсы рәсемгә (авторның үз фотографияләреннән башка) **аның хуҗасы яки авторлык хокукларына ия булган кешенең аларны бастырырга рәсми рөхсәте** булырга тиеш:

- оригиналдан копияләре алынган яки дәүләт яки шәхси архивларда, музейларда саклана торган иллюстрацияләрне файдаланганда, тиешле оешмадан яки шәхси заттан аны бастырып чыгаруга рөхсәт алырга кирәк. Оешмаларда (дәүләт музейларында, архивларда һ.б.) үзләренең рөхсәт формалары булырга мөмкин. Булмаган очракта автор журнал сайтының «Авторлар өчен» дигән бүлегендә тәкъдим ителгән үрнәктән файдалана ала.
- Музейларда саклана торган экспонатларның фотосурәтләрен файдаланган очракта, әлеге оешмадан аларны бастырып чыгару өчен рөхсәт алырга кирәк.
- Басылып чыккан китап, журнал яки башка басма яки интернеттан алынган иллюстрацияләрнең копияләрен кулланганда аларны кабат бастырып чыгару өчен: а) аларның авторыннан яки авторлык хокукына ия заттан; б) тиешле басмадан (гадәттә - нәшрият) рөхсәт алырга кирәк.
- Автор рәсемнәрнең авторлыгын яки моңарчы авторлык хокукларына ия булган затны ачыклауда, алардан рәсемне бастырып чыгару өчен язма рәвештә рөхсәт алырга җаваплы.
- Танылмаган һәм рөхсәт кәгазьләре булмаган иллюстрацияләр кабул ителми.

## VIII. График материал

Таблицалар, графикалар, диаграммалар мәкалә текстына аларга сылтама ясаганнан соң куела. Мәсәлән, (табл.1). Таблицаның, графиканың, диаграмманың исемен, үлчәү берәмлеген (%, сум һ.б.) һәм мәгълүматның вакытын (гасыр, ел) күрсәтү мәҗбүри.

Үрнәк:

*Таблица 1*

**Татарстан Республикасында катнаш никахларга мөнәсәбәт, 2014 ел, %**

| Җавап вариантлары | Шәһәр | Авыл |
|---|---|---|
| Хуплыйлар | 87 | 70 |
| Битараф | 10 | 28 |
| Җавап бирергә авырсыналар | 3 | 2 |